| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «КУАКБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КУАКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның 29 гыйнвары № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1,2 нче кушымталар нигезендә 2025 елның 01 февраленнән 9165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2024 елның 29 гыйнварындагы 2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, К.Маркс ур., 15 йорт, авыл мәдәният йорты бинасы; Сходнево-Чертанлы авылы -

Ирек ур., 5б йорт, авыл клубы бинасы; Чүте авылы - Тынычлык урамы, 8а йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2025 елның 29 гыйнварындагы 3 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2025 елның 1февраленнән

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе, сумн. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 3 464,53 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 1 741,41 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 3 959,43 |
| Барлыгы | **9 165,37** |

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2025 елның 29 гыйнварындагы 3 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «җирләү эше турында җирләү турында» ФЗ-8 12 статьясы нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2025 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе, сумн. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Гаүдәге төрү | 1 143,30 |
| 3. Табут һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2 321,22 |
| 4. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 1 741,42 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 3 959,43 |
| Барлыгы | **9 165,37** |